**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 11 июнендәге 1749 номерлы карары**

**«Сабантуй» татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү чорында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында**

«Сабантуй» татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү максатыннан, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. «Сабантуй» татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү чорында әлеге карарга кушымта нигезендә кирәк булганда Казан шәһәре автомобиль юллары буенча юл хәрәкәтен оештыруны 2025 елның 20 июнендә 18.00 сәгатьтән 2025 елның 21 июнендә 20.00 сәгатькә кадәр үзгәртергә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру схемасын эшләргә, аларны урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. юл хәрәкәтен оештыруны вакытлыча үзгәртү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән участокларда шәхси

мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эш оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә кирәк булганда юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябуны оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карарга кушымта нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;


2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге карарга кушымта нигезендә Казан шәһәренең автомобиль юллары буенча юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**


Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның  11 июнендәге
1749 номерлы карарына
кушымта

**Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясе схемасы**





Оренбургский Тракт
Фермское Шоссе
Тульская
ТК «ПОРТ 2»
Братьев Батталовых
ТК «ПОРТ 1»
а/д на «Лесной городок»
Парковка
VIP парковка
Термена
а/д на сады
Площадь Сабантуй
(вход на майдан)
Ново-Давликеевская


ул.Горьковское Шоссе